**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Поповка авыл җирлеге Советы**

**22.04.2024** **№ 04**

**2023 ел өчен Зәй муниципаль**
**районының Поповка авыл җирлеге**
**бюджеты үтәлеше турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 ел өчен Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисапны, керемнәрне чыгымнардан 119,6 мең сумга арттырып, керемнәр буенча 5835,9 мең сум күләмендә, чыгымнар буенча 5716,3 мең сум күләмендә һәм түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

1.1. 2023 елга бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары буенча күрсәткечләрне әлеге карарга 1 кушымта нигезендә;

1.2. 2023 елга бюджет керемнәре буенча күрсәткечләрне әлеге карарга 2 кушымта нигезендә;

1.3. 2023 елга бюджет чыгымнарын чыгымнарның функциональ структурасы бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре буенча бүлү буенча күрсәткечләрне әлеге карарга 3 кушымта нигезендә һәм бюджет чыгымнарының ведомство структурасы күрсәткечләрен әлеге карарга 4 кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының Поповка авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **И.Ә. Әмерханов**